| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

Шланга авылы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18 декабрь 2023 ел № 33/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы

Шланга авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы

нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советының 29.05.2023 № 27/1 карары (28.07.2023 28/2 редакциясендә) белән расланган, Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәнең 6 пунктына, түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 11 нче пунктта икенче җөмләне алып ташларга;

2) 17 пункт үз көчен югалткан дип танылырга тиеш;

3) 20 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

20. Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турында карар, әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән класс чины бирү турында тәкъдим кертелгәннән соң бер айдан да соңга калмыйча, органга яки җирле үзидарәнең класс чинын бирергә вәкаләтле вазыйфаи затына кабул ителергә тиеш.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң, гамәлдәге законнарда каралган очраклардан тыш, үз көченә керә

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы
Шланга авыл җирлеге башлыгы: И.И. Якупов